СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.06.2020 № 41/9

На № _________ от _____________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2011 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе турында» 9/9 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 6 февралендәге 66 номерлы карарын үтәү йөзеннән, район уставы нигезендә, кадрлар үзгәреше сәбәпле, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2011 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе турында» 9/9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составыннан чыгарырга:

Нурхәмитова Эльмира Давран кызын;

1.2. балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составына кертергә:

Шаябтдинов Айрат Айдар улын – полиция участок уполномоченныйлары бүлеге һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсе башлыгы, полиция майоры (килешү буенча).

2. Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясен яңа составта кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 10 июнь 41/9 номерлы карарына кушымта

## Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Закиров Р.И. | Тукай муниципаль районы Башлыгы урынбасары – комиссия рәисе; |
| Бариев И.Ш. | район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары – комиссия рәисе урынбасары; |
| Хөснетдинова Г.Т. | район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече – комиссиянең җаваплы секретаре. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Габдуллин Н.С. | «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Фазылова С.Г. | Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе федераль казна учреждениесенең Тукай районы буенча филиалы башлыгы (килешү буенча); |
| Гәрәев И.Р. | район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Әхмәтҗанова Э.М. | район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Сухорук А.А. | ТР буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Тукай муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Шаябтдинов А.А. | полиция участок уполномоченныйлары бүлеге һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсе башлыгы, полиция майоры (килешү буенча); |
| Ахунова Э.Н. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районындагы халыкны социаль яклау бүлеге башлыгы; |
| Сиврюк Т.Н. | Яр Чаллы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Тукай муниципаль районы буенча филиалы мөдире (килешү буенча); |
| Хәмәтҗанова Г.Х. | район Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы мөдире; |
| Сабирҗанов Г.Г. | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы (килешү буенча); |
| Валькаева А.Т. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге әйдәп баручы белгече - балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия белгече. |